КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 7 июль г.Казань № 648

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибе турында» 2017 ел, 21 сентябрь, 705 нче карары белән расланган акчалары максатчан тотылырга тиешле керемнәр исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тиешле финанс елына Татарстан Респуб-ликасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибе турында» 2017 ел, 21 сентябрь, 705 нче карары белән расланган акчалары максатчан тотылырга тиешле керемнәр исемлегенә, аңа түбәндәге эчтәлекле 20 – 23 пунктлар өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«20. Онкология авыруларына каршы көрәш өлкәсендә алдынгы тәҗрибә буенча белем бирү һәм аны тарату хезмәтләре күрсәтүдән алынган керемнәр.

21. Яман шешкә каршы дару препаратларына клиник тикшеренүләр үткәрүдән алынган керемнәр.

22. Кан сывороткасындагы карбогидрат-дефицитлы трансферринны сыйфатлы һәм микъдари билгеләүгә тикшеренү хезмәтләре күрсәтүдән алынган керемнәр.

23. Кара һәм төсле металл ватыкларын, макулатураны сатудан алынган керемнәр.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин